| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2017 Казан ш. № 5-20/тэ

2018-2020 елларга «Теплокоминвест» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (куәте) өчен тарифлар билгеләү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Теплокоминвест» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) шушы карарның 1 кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Шушы карарның 2 кушымтасы нигезендә 2018-2020 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып, тарифлар формалаштыру өчен җайга салуның дәвамлы чорына билгеләнә торган җайга салуның дәвамлы параметрларын билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 03.11.2017 № 5-20/тэ карарына 1 кушымта

## «Теплокоминвест» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2018-2020 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салучы оешманың аталышы, Тариф төре | Ел | Су | Басым белән сайлап алынган пар | | | | Әче һәм редуцияләштерелгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см2 кадәр | 2,5тән 7,0 кг/см2 кадәр | 7,0дән 13,0 кг/см2 кадәр | югары 13,0 кг/см2 | |
| | Биектау муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Теплокоминвест» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 1731,19 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 1763,73 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1763,73 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1832,47 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1832,47 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1861,35 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 03.11.2017 № 5-20/тэ карарына 2 кушымта

Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2018-2020 елларга җайга салуның дәвамлы чорына билгеләнә торган җайга салуның дәвамлы параметрлары

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | җылылыкның чагыштырма сарыфы | технологик сарыфлар зурлыгының җылылык челтәренең матди сыйфатламасына карата мөнәсәбәте | технологик сарыфлар |
| | | | мең сум | % | кг у.т./Гкал | Гкал/м$^2$ | Гкал |
| | Биектау муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Теплокоминвест» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2018 | 1248,37 | 1 | 159,7 | 2,28 | 217,1 |
| | | 2019 | X | 1 | 159,7 | 2,28 | 217,1 |
| | | 2020 | X | 1 | 159,7 | 2,28 | 217,1 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге